ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА МЕНЗЕЛИНСКА МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МИНЗӘЛӘ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

от 21.04.2021

№ 44

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан башка муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 2014 елның 29 октябрендәге 498 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатыннан карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан башка муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2014 елның 29 октябрендәге 498 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.5 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган белешмә (өземтә) астында түбәндәгеләр аңлана: хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт кенәгәсеннән архив өземтәсе, элекке яшәү урыныннан белешмә, көнкүреш характеристикасы»;

2.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бирүче түбәндәге документларны тапшыра:»:

1) шәхесне раслаучы документ;

2) мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ, мөрәҗәгать итүче вәкиленең муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткән очракта (физик затларның законлы вәкилләреннән тыш);

3) гариза:

- документ формасында кәгазьдә (1 нче номерлы кушымта);

- «Электрон имза турында» 06.04.2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон таләпләренә туры китереп, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткәндә, имзаланган электрон формада (тиешле мәгълүматларны интерактив формага кертү юлы белән тутырыла);

4) Әгәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче булмаган затның персональ мәгълүматларын эшкәртү кирәк булса һәм, әгәр федераль закон нигезендә, мондый персональ мәгълүматларны эшкәртү күрсәтелгән затның ризалыгы белән башкарылырга мөмкин булса, мөрәҗәгать итүче муниципаль хезмәт алу өчен мөрәҗәгать иткәндә күрсәтелгән затның яисә аның законлы вәкиленең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын алуны раслаучы документлар тапшыра. Рөхсәт алуны раслаучы документлар, шул исәптән, электрон документ формасында да тапшырылырга мөмкин.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Башкарма комитетта шәхси мөрәҗәгать иткәндә ала ала. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза бирүче гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшыра (җибәрә) ала:

- шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);

- почта аша.

Гариза һәм документлар шулай ук гариза бирүче тарафыннан Республика порталы аша электрон документлар рәвешендә тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин»;

1 нче кушымтаны кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итәргә;

2 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Җитәкче Р. Ф. Ягафаров

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Минзәлә
муниципаль районы
дата ________________ № _____

_______________________________________________
(жирле үзидарә органы исеме
_______________________________________________
муниципаль берәмлек башлыгы)

_______________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

_______________________________________________,
(паспорт мәгълүматлары)

түбәндәге адрес буенча яшәүче:
____________________

_______________________________________________
(мәгълүматлар, яшәү урыны буенча теркәлү)

_______________________________________________

Ышанычнамә
буенча______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме,
ышанычнамә номеры)

_______________________________________________

_______________________________________________
(телефон)

**Гариза**

Белешмә (өземтә) бирүегезне сорыйм
_____________________________________________
(белешмә төрен күрсәтергә)

Адрес буенча:
_______________________________________________________________

Гаризага түбәндәге документларны кушып бирәм:
1. _______________________________________________________________
2. _______________________________________________________________
3. _______________________________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында хәбәр итүегезне сорыйм:
ысул белән ____________________________________

________________/_________________/____________________________
(дата) (имза) (Ф. И. Ат.ис..)